КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 24 апрель г.Казань № 517

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 3 май, 259 нчы; 2019 ел, 27 февраль, 128 нче; 2019 ел, 27 июль, 626 нчы; 2019 ел, 30 декабрь, 1236 нчы; 2021 ел, 21 май, 360 нчы; 2022 ел, 10 июнь, 545 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1328 нче; 2023 ел, 14 март, 250 нче; 2023 ел, 7 август, 952 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1753 нче; 2024 ел, 16 декабрь, 1142 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

1.7 пунктта «(алга таба – «Электрон бюджет» системасы»)» сүзләреннән соң «(техник мөмкинлек булганда)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.31 пункт өстәргә:

«3.3[1]. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү Министрлык тарафыннан, заявкаларны кабул итү тәгәлләнгән дата җиткәнгә кадәр, түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

3.15 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге беркетмәнең яңа версиясен булдыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

5.3 пунктының дүртенче абзацында «әлеге Тәртипнең 5.4 пунктында каралган очракта, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.4 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5.6 пунктның җиденче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 пунктта «грант» сүзен «грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктның беренче абзацында «Грант» сүзен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «грант» сүзеннән соң «акчасы» сүзен өстәргә;

икенче абзацта татар текстында «грантны кире кайтару көненә» сүзләрен «грантны (грантның бер өлешен) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару көненә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры | А.В.Песошин